وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№7 (176). 15 февраль 2013 / 5-рабыгыль-әүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



РИШВӘТ ▷2◁

Тәгълим-тәрбия системасында Коръәннең роле ▷3◁

Әле соң түгел ▷4◁





## Барлык гамәлләребезне Аллаһы Тәгаләгә генә багышлыйк!

**Безнең һәрбер адымыбыз тирә-ягыбызны әйләндереп алган мохиткә юнәлтелгән. Бу даими процесс - һәр кеше дөньяга ниндидер йогынты ясый. Без башкалардан изгелек, киң күңеллелек һәм ачык йөз көтәбез, өмет итәбез. Ләкин үзебез дә башкаларга карата шундый була алабызмы соң? Кешеләрдән әхлак, иҗтимагый активлык, шәхси мәнфәгатьләрен онытып, башкаларга файда китерүне таләп иткәндә без үзебездән тагын да күбрәкне таләп итәргә тиешбез.**

Мәһабәт һәм матур йорт төзү нигез салудан түгел, ә ниндидер бер матур, якты, мөһим бина кору ниятеннән башлана. Һәм инде шуннан соң гына һәрбер гамәлебез ниятебезгә туры киләчәк. Барлык эшләребез дә Аллаһы Тәгаләгә багышланган булырга тиеш, моның шулай икәнен бары тик үзебез һәм Раббыбыз гына белә. Башка кешене тикшерү, бәяләү, аның гамәлләренең асылын чамаларга тырышу Аллаһы Тәгаләгә багышлаган үз эшебезне ташлауга тиң. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәләмнең Сөннәтендә болай диелгән: "Яхшы мөселман үз кимчелекләрен эзләгәндә, башкаларда кимчелекләр күрү өчен вакыт тапмас". Барыбыз да бу сүзләргә колак салсак, ыгы-зыгылардан, талашлардан һәм сугышлардан котылып калу белән бергә, һәрберебез үз эшен башкарып, бербөтен ныгытма төзи алачакбыз.

Шуның белән беррәттән, барлык өметләребезне үзебезгә багларга тиешбез. Еш кына без кылган яхшылыкларыбыз өчен башкалардан изгелек көтәбез. Ләкин әйләнә-тирәдәгеләр ниятләребезне, гамәлләребезне ничек аңлаганны белә алабызмы соң?! Шуңа күрә дә башкачарак уйлау дөресрәк булыр: һәрвакыт пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) кебек кешеләр үрнәген истә тотып, игелекле гамәлләрне үзебездән көтик. Һәм бары тик Аллаһы Тәгаләнең генә рәхим-шәфкатенә өметләник.

Гомеребезнең һәрбер минуты - хезмәт, аның җимешләрен без ахирәттә татыячакбыз. Ялкаулыкны, эгоизмны, ачуны, кешеләргә карата битарафлыкны, белемсезлекне һәм рухи көчсезлекне җиңү - тормышыбыздагы төп бурыч. Шуңа күрә башкаларның сүзләрен һәм гамәлләрен тикшергәнче, безгә үз-үзебезне тәрбияләргә, кылган гамәлләребез турында уйланырга кирәк. Үз-үзеңне аңлау, тану, өйрәнү - Аллаһы Тәгаләне аңларга тырышуның бер юлы ул.

**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Дидия нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНӘ - 15 ЕЛ

**Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте оешуга 15 ел тулды. Ул үз эшчәнлеген 1998 елның 14 февраленнән алып бара. Бу вакыт эчендә Татарстанның барлык районнарында мөфтиятнең структурасын, оешмаларын булдыру һәм аларның актив эшчәнлеген тәэмин итү юнәлешендә күп гамәлләр кылынды.**



15 ел дәвамында алып барылган җитди эшчәнлек нәтиҗәсендә бүгенге көндә барлык мәхәлләләрдә дини белем бирү, мәдәни, хәйрия һәм дәгъват чаралары оештырыла. Иң мөһиме - алар, татарстанлыларның рухи ихтыяҗларын, омтылышларын истә тотып, даими үткәрелә. Бүгенге көндә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте 45 мөхтәсибәттән, 9 казыяттән тора. Татарстанда мең өч йөздән артык мәчет, БДБ илләрендә иң алдынгы мөселман уку йортларының берсе булган Россия ислам университеты эшли.

Нәзарәт Татарстан мөселманнары исеменнән дәүләт органнары, шулай ук башка төбәк һәм илләр белән элемтәләр булдыра, хезмәттәшлек итә.

Мөфтият структурасына түбәндәге бүлекләр керә: халыкара элемтәләр, вакыф милке белән идарә итү, уку-укыту, ярдәм күрсәтү һәм хәйрия, яшьләр белән эшләү, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте белән бәйләнешләрне җайга салу, дәгъват һәм мәгълүмат, нәшрият бүлекләре. Шулай ук "Хәләл" стандартлары комитеты, "Зәкят" хәйрия фонды һәм Голәмалар шурасы.

Бүгенге көндә динебезнең йогынтысы арта бара, ул социаль, мәдәни, икътисади һәм башка өлкәләрдә мөһим урыннарны били. Әмма глобальләшү үзенең мәгълүмати басымы белән милли үзенчәлекләрне, дини кыйммәтләрне юкка чыгарырга омтыла. Менә шушындый заманда татар халкына милләт буларак сакланып калырга ярдәм иткән мөселман дини оешмаларын яклау һәм үстерү - мөһим проблемаларның берсе булып кала бирә. Шуңа күрә илебездәге иң зур дини оешмаларның берсе булган Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең эшчәнлеге республика һәм барлык мөселманнар өчен дә зур әһәмияткә ия.

Хәзерге этапта Диния нәзарәте җәмгыятьтә ихтыяҗ арта баруга җавап итеп, Татарстан өммәтен үстерү, мөселманнарның хәлен яхшырту, дини-милли мирасыбызны барлау һәм аны саклау, рухи кыйммәтләребезне җиткерү максатыннан, төрле проектларны тормышка ашыру белән шөгыльләнә. Республикабызда яңа мәчетләр ачыла, мәхәлләләрдә, дини мәгариф оешмаларында (мәдрәсәләрдә) эшләр өчен белемле кадрлар әзерләү актив рәвештә алып барыла.

## 15 еллык тәҗрибәбез – зур байлык



Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә - 15 ел! Әлеге юбилей барлык мөселманнар, мәхәлләләр, мөхтәсибәтләр өчен мөһим вакыйга. Чөнки без барыбыз да бер структураны тәшкил итәбез, бер үк бурычларны хәл итү өчен көчебезне куябыз.

Нәзарәтнең үткән чордагы эшчәнлегендә барчабызның да - бәлки кемнеңдер әзрәк, кемнеңдер күбрәк - өлеше бар. Ул елларда тәҗрибә тупланылды, дин-дәгъват эшләрендә яңа, үтемлерәк формалар эзләү барды. Аларның күбесе эш барышында уңышлы кулланылды. Әлбәттә, бу елларда күпмедер дәрәҗәдә ялгышулар, үзебезнең җирлектә хәнәфи мәзһәбе буенча формалашкан һәм инде мең елдан артык яшәү рәвешебезне тәшкил иткән динебез кыйммәтләрен санга сугып бетермәү күренешләре дә булмады түгел. Әмма инде алар әкренләп тарихта кала бара. Татарстан мөселманнарының чираттан тыш узган V Корылтае (2011 ел, 13 апрель) Диния нәзарәте эшчәнлегендә эчке проблемаларны хәл итүгә таба чын-чынлап борылыш булды. Без бүгенге көндә аның нәтиҗәләрен ачык күрәбез. Имамнар аттестация узды, мәхәлләләр тәртипкә китерелде. Мөхтәсибәтләргә, мәдрәсәләргә финанс ярдәме даими төс алды. Дини мәгариф системасы, традицион ислам кыйммәтләренә нигезләнеп, яңабаштан корылды, тормышыбызда Мәүлид бәйрәмнәре, дини җыеннар һәм башка йолалар яңарды. Болар барысы да рухи дөньябызны баетуга, телебезне, динебезгә нигезләнгән гореф-гадәтләребезне саклап калуга, бабаларыбыз калдырган мирасны кадерләп саклый һәм куллана белүгә юнәлдерелгән. Без соңгы вакытта җәмгыятебездәге тынычлыкны, милләтләр татулыгын тәэмин итүдә дин әһелләренә нинди мөһим, зур роль бирелгәнлеген тагын да ныграк аңладык. Узган җәйдәге теракт безне чын-чынлап тетрәндерде. Ул артка юл юклыгын, радикал, экстремизмны фәкать рухи көрәш, халыкка дөрес гыйлем бирүгә нигезләнгән системалы эш белән генә бетерергә мөмкин икәнлеген күрсәтте.

Диния нәзарәтенә 15 ел тулган бу көннәрдә без күбрәк киләчәк турында уйлыйбыз, планнар корабыз. Һәм шуны аңлыйбыз: фикер-мәзһәб бердәмлеге булганда гына без алга куйган максатларыбызга ирешәчәкбез, җәмгыять тарафыннан үзебезгә йөкләнгән вазифаны уңышлы үти алачакбыз. 15 еллык эш тәҗрибәбез - ул безнең өчен зур байлык.

**Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛА, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Президиум әгъзасы, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе**



# РИШВӘТ

**Кызганыч, бүгенге көн-дә ришвәт бирү киң таралган. Бу күренешкә бик күп җирдә юлыгасың: мәктәптә, балалар бакчасында, югары уку йортларында, хастаханәләрдә... Әлеге мәсь-әлә буенча күп эшләр эшләнә, аны бетерү өчен төрлесен кулланып карыйлар, әмма ришвәтчелек елдан-ел үсә бара.**

Ислам дине ришвәт бирүне һәм алуны катгый рәвештә тыя. Алучы, бирүче кебек үк, Аллаһы Тәгаләнең ләгънәтенә дучар була. Әбү Һөрәйрә исемле сәхабә (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять итүдән билгеле, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) үзенең бер хәдисендә: "Ришвәт бирүчене һәм алучыны Аллаһ ләгънәт кылды", - дигән (Тирмизи). Шушы хәдиснең икенче риваятендә: "... Алар арасында булган арадашчыны да", - дип әйтелгән (Әхмәд бин Хәнбәл).

Ришвәтче икенче берәүгә акча яки мал биреп, үзенә лаек булмаган әйберләргә ия була, ягъни гаделсезлек кыла. Аллаһның Рәсүле (сгв) ришвәт алучыны да ләгънәт кыла, чөнки ул шәригатькә каршы гамәл башкара, Аллаһның рәхмәтеннән мәхрүм кала. Шуңа күрә Аллаһның газабын һәм ачуын булдырмас өчен, хак мөселманга шөбһәле нәрсәләрдән ераграк булырга, һәрвакыт һәм һәр урында гадел булырга тырышу лазем.

Ришвәтне тыю хакында Аллаһы Тәгалә "Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 188 нче аятендә болай ди:

لى الحكام لتأكلوا فريقا من أموال الناس بالإثم وأنتم تعلمون

"Бер-берегезнең малын гаделсезлек белән тартып алып ашамагыз. Белеп торганыгыз көе кешенең малын өлешчә генә булса да махсус тартып алыр өчен, хөкемдарларга ришвәт бирмәгез".

Аллаһ Раббыбыз ришвәт алуны гына түгел, хәләл булмаган табышка ирешү максаты белән үзеңнең дәрәҗә-вазифаңны кирәгеннән артык арттыруны да тыйган. Шулай ук ялганлау, кемнеңдер малын хаксыз куллану һәм киметеп үлчәү дә хәрәм гамәлләрдән санала. Сәүдә алып барганда алдау-йолдау юлы белән баерга теләүчеләр Кыямәт көнендә Аллаһның җәзасын алачак. Бу турыда Коръәни-Кәримдә болай диелә:

طففين الذين إذا اكتالوا على الناس يستوفون

ألا يظن أولئك أنهم مبعوثون ليوم عظيم يوم يقوم الناس لرب العالمين

"1. Киметеп үлчәүчеләргә ләгънәт төшәр. (Аларның Кыямәттәге хәле коточкыч яман булыр.) (2) Андыйлар (комсыз, намуссызлар) үзләренә үлчәгәндә, мул итеп, артыгы белән үлчәтеп алалар. (3) Кешеләргә үлчәгәндә киметеп бирәләр. (Яки үлчәүне бозалар, яки гер авырлыгын киметәләр, яки үлчәнәчәк әйберне ким салалар.) (4) Яңадан тереләчәкләрен (каты җәзага тартылачакларын) белмиләрмени соң алар? (5) Бөек бер көндә (6) галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ (каршында җавап тотар) өчен кешеләрнең каберләреннән кубарылып чыгасы көн килеп җитәр" ("Мутафифин (Киметеп үлчәү)" сүрәсенең 1-6 нчы аятьләре).

"Рахмән" сүрәсенең 9 нчы аятендә:

وأقيموا الوزن بالقسط ولا تخسروا الميزان

"Үлчәүне гаделлек белән тотыгыз һәм киметеп үлчәмәгез", - диелә.

Ришвәт бирүдән баш тарту мөмкинме? Бу "авыру"ны дәвалап буламы? Әгәр дә без тарихыбызга, бигрәк тә мөселман патшаларының тормыш юлына игътибарыбызны юнәлтсәк, бу мәсьәләләрне чишү күренешләренә тап булырбыз, инша Алла!

Гомәр бин Габделгазиз исемле хәлифә (Аллаһ аны рәхмәтеннән ташламаса иде) тормышыннан (күп кенә галимнәр аны бишенче тугры хәлифә дип атый) бер мисал китерәсем килә. Ул алма яраткан. Көннәрдән бер көнне Гомәр бин Габделгазиз үз өендә мөселман кардәшләре белән утырганда: "Мин хәзер, рәхәтләнеп, алма ашар идем", - дигән. Шулчак күршесе аңа уйламаганда-көтмәгәндә бер кәрзин алманы бүләк итеп җибәргән. Хәлифә, күршесенә рәхмәт хаты язып, бүләген аңа кире озаткан. Кешеләр хәлифәдән: "Ни өчен сез яраткан алмаларыгызны алып калмадыгыз?" - дип сораганнар. Хәлифә үз җавабын болайрак кайтарган: "Пәйгамбәребез (сгв) бүләкләр кабул иткән үзе, ләкин мин бу бүләкнең ришвәт булуы мөмкин дип курыктым".

Фудаил бин Гияд дигән вәли (Аллаһ аны рәхмәтеннән ташламаса иде): "Әгәр минем Аллаһ кабул итә торган бер генә догам булса, мин аны патша өчен кылыр идем", - дигән. Кешеләр бу сүзләрне ишетеп гаҗәпләнгәннәр һәм аннан аңлатма алырга мәҗбүр булганнар. Фудаил болай дип җавап биргән: "Әгәр үзем өчен генә сорасам, файдасы миңа гына булачак. Патша өчен сорасам, ул изгелеккә ирешер һәм бар халык изге күңелле булыр".

Хикмәт ияләре: "Кешеләрнең холкы - хакимнәрнең холкыдыр. Хакимнәр нәрсә эшләсә, халык та шуны ук эшләр", - дигән. Шулай итеп, хакимнәр җәмгыятьтәге җитешсезлекләр, бозыклыклар өчен җаваплы булуларын гел истә тотмасалар һәм үзләрен үзгәртү, камилләштерү юлына басарга теләмәсәләр, дөньяның яхшы якка үзгәрәчәге бик тә шикле.

Бөек ислам галиме, алдынгы фикер иясе Әбү Хәмид әл-Газзали (Аллаһ аны рәхмәтеннән ташламаса иде) болай дип язган: "Мөселманнарның хөкемдары Вәлид бин Габделмалик төзелеш эшләренә һәм авыл хуҗалыгы үсеше өчен игътибарлы булган, ә икенче бер хаким (Сөләйман бин Габделмалик) күңел ачу мәҗлесләрен хуп күргән". Гомәр бин Габделгазиз исә үзенең тәкъвалыгы, изге күңелле булуы белән мәгълүм. Шул заманда яшәгән бер галимнең: "Вәлид патша вакытында төзелеш эшләренең киң таралган булуын һәм кешеләрнең бакчаларга йөрүен күрмәгән булсам, хакимнәрнең холкы халыкка күчә икәнлегенә төшенмәс идем. Сөләйман хаким булып киткәч, халыкның кызыксынуы ашау-эчүгә күчкәнлекне сиздем. Барысы да бер-берсеннән өстәлгә нинди ризыклар әзерләп куюларын һәм нәрсә ашауларын белешә иделәр. Ә менә Гомәр бин Габделгазиз вакытында кешеләрнең күп тапкырлар Коръән укуларына һәм Аллаһка итагать итүдә тырышлык күрсәтүләренә юлыктым", - дигән сүзләре безнең көннәргә дә килеп җиткән.

Үзенең гаделлеге белән танылу алган фарсы патшасы Әнуширван хакимлеге вакытында бер кеше үзенә җир кишәрлеге сатып алган. Күпмедер вакыт узганнан соң, бу кеше шул җирдә хәзинә-байлык ятуын күргән. Бу хакта ул җирнең элеккеге хуҗасына сөйләгән. Тегесе аңа: "Сиңа җиремне сатканчы андагы хәзинәләргә тап булганым булмады, шуңа күрә табылган ул байлыклар синең үзеңә булсын", - дип җавап биргән. Ләкин җиргә ия булган яңа хуҗа моның белән килешмәгән һәм: "Чит кешенең малы миңа кирәк түгел, җир булса җитә", - дигән. Шулай итеп, җирнең элеккеге хуҗасы хәзинәне үзенә лаек дип тапмаган, яңа хуҗа да табылган хәзинәләрне үзенә калдыру яклы булмаган. Озакламый аларның бәхәсләшүләре Әнуширван патшага кадәр барып җиткән. Ул бу кешеләрнең гадел булулары өчен сөенгән һәм бәхәсне хәл итү юлын да күрсәткән: аларга киңәш итеп, ул балаларын өйләнештерергә һәм хәзинәне яшьләргә бүләк итәргә кушкан. Әнуширван үзе дә гадел булганлыктан, халык гаделлек белән яшәргә тырышкан. Әгәр бу хәл гадел булмаган патша заманында булса, һәрберсе: "Хәзинә минеке!" - дип бәхәсләшкән булыр иде...

Әлбәттә, хакимнәребез генә түгел, һәрберебез дә бу турыда уйланырга, ришвәтчелектән ерак торырга тиеш. Ришвәт бирү яки алу юлы белән бу дөньяда күп кенә хыял-максатларыбызга ирешә алсак та, аның ахыры бик аяныч булачак: мәңгелек бәхет-сәгадәттән мәхрүм калуыбыз ихтимал.

Гамр бин әл-Гас исемле сәхабә (Аллаһ аннан разый булса иде) риваять итүдән билгеле, Аллаһның Рәсүле (сгв): "Риба таралганнар арасында корылык яки уңыш булмауга ирешмәгән халык юктыр, шулай ук ришвәт таралганнар арасында да курку чолгап алмаган халык юктыр", - дигән (Әхмәд бин Хәнбәл).

Ришвәтчелек имансызлыктан, кеше малын ашау өчен курыкмаудан һәм хәләл белән хәрәмне аермаудан килеп чыга. Үзен хак мөселман дип санаган бәндә ришвәткә якын да атламаска тиеш. Рәсүл әкрәм галәйһиссәлам: "Мөэмин бер гөнаһ эшләгән вакытта аның калебендә бер кара тап барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итеп, бу гөнаһтан ваз кичсә, аның калебе пакьләнә. Әгәр ул тәүбә итмәсә һәм гөнаһлы гамәлләр кылуын дәвам итсә, аның калебендә кара таплар саны арта һәм калебе карала", - дигән (Ибн Мәҗә). Бу хәдисне һәрдаим истә тотсак иде!

Мөхтәрәм мөселманнар! Ришвәт алып яки биреп үз калебләребезне каралтмасак иде. Кыямәт көнендә: "Малларыгызны ничек таптыгыз һәм аларны кая сарыф иттегез?" - дигән сорауларга Аллаһ каршында җавап бирәчәгебезне беркайчан да онытмасак иде!

**Нияз хәзрәт САБИРОВ,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы,**
**Казан ислам колледжы директоры урынбасары**

# Тәгълим-тәрбия системасында Корьәннең роле

*(Ахыры. Башы газетабызның 8 февраль санында)*



**Соңгы вакытларда Корьәни-Кәримнең аерым нөсхәләрен аеруча нәзакәтле, нәкышле итеп эшләүгә игътибар бирелә. Мәсәлән, шуларның берсе Италия осталары тарафыннан эшләнгәне - 1,5х2 метр үлчәмендәге Корьәни-Кәрим 800 килограмм авырлыкта. Аның малахиттан эшләнгән тышлыгы мәрҗән, куе яшел төстәге авантюрин, топаз, кызыл йәшәм (яшма), аметист кебек асылташлар белән бизәлгән.**

Иң әүвәл Корьәни-Кәрим бары тик гарәп телендә генә нәшер ителгән. Көнбатыш Европада Корьәни-Кәримнең латин телендәге тәрҗемәсе 1144 елда ук дөнья күрә. Аннан соң ул итальян (1513 ел), алман (1616 ел), француз (1647 ел), инглиз (1648 ел) телләренә тәрҗемә ителә. Бүгенге көндә бу илләрдә Корьәннең утызга якын тәрҗемәсе булып, алар арасында сүзгә-сүз һәм мәгънәви тәрҗемәләре дә бар.

Россиядә Корьәннең заманында күренекле галимнәрдән саналган Пётр Посников тарафыннан башкарылган рус телендәге тулы тәрҗемәсе 1716 елда басылып чыга. 1783 елда галим Савари тәрҗемәсе бастырыла. 1790 елда Казанның Беренче ирләр гимназиясе директоры булып эшләгән һәм шәрекъ телләрен укытуның ялкынлы тарафдары булган академик М.М. Верёвкин тәрҗемәсе нәшер ителә. 1792 елда мәшһүр тәрҗемәче А.Колмаков Корьәни-Кәримнең рус телендәге дүртенче тәрҗемәсен бастыра. 1854 елда А.Казимирский, 1864 елда К.Николаев тәрҗемәләре дөнья күрә. Моңа кадәр Корьәннең рус телендәге тәрҗемәләре француз, инглиз телләрендәге басмаларга нигезләнеп башкарылса, XIX йөзнең соңгы чирегеннән турыдан-туры гарәп теленнән тәрҗемә ителгәннәре дөнья күрә башлый. Рус телендәге шундый тәрҗемә авторларының берсе шәрекъ һәм гарәп телләре белгече Г.С. Саблуков була. 1877 елда аның тәрҗемәсендә Корьәннең яңа басмасы Казанда нәшер ителә. 1894 һәм 1907 елларда ул кабаттан бастырып чыгарыла. Гомере буе Корьәнне рус теленә тәрҗемә итү белән шөгыльләнгән һәм "Корьән тәрҗемәсенә кушымталар", "Корьән турында мәгълүматлар", "Мөхәммәд динендәгеләрнең кыйбла турындагы фикерләре" кебек хезмәтләр язып калдырган Г.С. Саблуков тәрҗемәсе тулы бер гасыр буена бу өлкәдә рус фәне һәм җәмгыяте ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндергән мөһим чыганакка әверелә. Корьәннең рус телендәге чираттагы басмасы бары тик 1963 елда гына дөнья күрә. Аның авторы - бөтен гомерен Корьәнне өйрәнүгә багышлаган, югары уку йортларында лекцияләр укыган атаклы галим, академик И.Ю. Крачковский. Бу тәрҗемә үзенең төгәллеге, текстларның аныклыгы-камиллеге һәм тулылыгы белән аерылып тора. Аның яңа басмалары 1986 һәм 1990 елларда нәшер ителә.

Ислам дөньясында Корьәнне мөселман халыклары телләренә тәрҗемә кылу катгый тыелган булса да, төрле дәверләрдә уйгыр, фарсы, урду, төрек телләренә тәрҗемә ителгәнлекләре мәгълүм. 1960 елда күренекле төрек галимнәре Хөсәен Атай һәм Ятар Котлыай тарафыннан Изге Китапның төрекчәгә яңа тәрҗемәсе дөнья күрде, аннан соң да аның яңадан-яңа басмалары нәшер ителде. 1991 елда Бакуда Корьәннең азәрбайҗан теленә яңа тәрҗемәсе (тәрҗемәчеләр З.Бониятов, В.Мәмәдалиев, А.Пашазадә тырышлыгы белән) басылып чыкты.

1911 елда мәшһүр дин галиме Муса Бигиев Корьәнне татар теленә тәрҗемә итә. Әмма ул тәрҗемә нәшер ителмичә кала. Зыяэтдин Кәмалиның "Корьәни-Кәрим тәрҗемәсе" дә шундый язмышка дучар була.

1914 елда Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин тәрҗемәсенең аерым өлешләре дөнья күрә. Корьәни-Кәримнең татар телендәге башка тәрҗемәләре билгеле түгел. 1936 елда Каһирәдәге Әл-Әзһәр ислам университетының күренекле дин галимнәреннән махсус



һәйәт төзелә һәм Корьәнне башка телләргә тәрҗемә кылу мәсьәләсе уңай хәл ителә.

Тәфсир, гыйльме тәфсир (гарәпчәдән "аңлатып бирү") - Корьәннең фәлсәфи аңлатмасы. Корьәннең үзе кебек үк, тәфсирләр дә исламият тарихын, аның гасырлар дәвамындагы эволюциясен өйрәнү өчен әһәмиятле чыганак булып тора. Борынгы тәфсирләр, нигездә, гарәп телендә язылган. Тәфсир эшләүне беренче булып Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләмнең туганнан-туган кардәше Габдулла бине Габбас башлап җибәргән. Башка тәфсирчеләр аны үзләренең остазы итеп кабул иткәннәр. Сөнниләрдән тәфсир язучы - атаклы голәмаларның берсе, күренекле тарихчы һәм дин галиме Әт-Тәбари. Аның "Тәфсире әл-Корьән" дип аталган хезмәте бу өлкәдә аңа кадәр эшләнгәннәрнең бөтенесен үзенә туплаган. Бу хезмәтнең тулы басмасы 1906 елда Каһирәдә 30 җилдтә басылган. Шулай ук Зәмәхшәри Бәйдави, Фәхретдин Рази, Хөсәйни, Җәләлетдин әс-Суюти тәфсирләре бөтен дөнья күләмендә шөһрәт казанган һәм киң таралган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) өммәтендәге мөселман татарлар өчен дә Корьәни-Кәримнең татарча тәфсирләренә ихтыяҗ артканнан-арта бара. Дин тотучыларның иң зур күпчелеге гарәп телен аңламый. Димәк, Изге Китапта ниләр язылганын да белеп бетермиләр. Ә Корьәнгә киңәйтелгән мәгънәви аңлатма-тәфсир кылганда гына аның бөеклегенә, инсаннарның яшәү рәвешенә тугры юл күрсәтүче Изге Китап булуына төшенергә мөмкин.

Мәгълүм булганча, Корьәнне башка телләрдә аңлату-шәрехләү беркайчан да тыелмаган. Моның шулай икәнлеген дәлилләп, атаклы гыйлем иясе Шиһабетдин Мәрҗани дә үзенең "Нәзурәтел-хак" ("Хаклыкка бер караш") дип аталган хезмәтендә Корьән һәр чорда яңача тәфсир ителергә тиеш, ягъни Корьән сүрәләрендәге аятьләрне заман сулышын тоеп тәфсир итү яхшырак, дигән фикерен җиткерә.

Элегрәк кульязма рәвешендә таралган Корьәннең татарча тәфсирләре XIX йөзнең икенче яртысында басма хәрефләр белән нәшер ителә башлый. Шул дәвернең 80 нче елларында Хөсәен һәм Мөхәммәтзариф Әмирханнар тарафыннан эшләнгән 2 җилдлек "Тәфсире фәваид" ("Файдаларның тәфсире") Казанда басылып чыга. XX гасыр башларында, гарәп шрифтлары белән эш итүче матбагалар ачылгач, Корьән тәфсирләре күбрәк нәшер ителә башлый. Бу елларда Шакирҗан Хәмидинең "Һәфтияк-Шәриф тәфсире" (Казан, 1906), Шәйхелислам Хәмидинең "Әл-Иткан фи тәрҗүмәтил-Куръән" (Казан, 1907), Габденнасыйр Курсави һәм Ногман әс-Самани тарафыннан шәрехләнгән "Тәфсире Ногмани" (Оренбург, 1907), Мөхәммәтсадыйк Иманколыйның "Тәһсилел бәян фи тәфсире Корьән" (Казан, 1911), Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның "Татарча Корьәни тәфсир" (Казан, 1914) басмалары дөнья күрә.

Соңгы вакытларда Корьәни-Кәримнең берничә яңа тәфсире нәшер ителде. Без аларга Фәрит хәзрәт Сәлман, Рабит Батулла, Камил хәзрәт Бикчәнтәев, Мөхәммәтъяр Нәҗметдин мөәллифлегендә чыккан басмаларны кертәбез. Һичшиксез, татар телендәге Корьән тәфсирләре буш урында гына барлыкка килмәгән. Бу өлкәдә эшләүче голәмалар, төрле елларда нәшер ителгән Корьән тәрҗемәләреннән, тәфсирләреннән нәтиҗәле файдаланганнар. Мәсәлән, татар галимнәре Исмәгыйль Бохариның "Китабүт-тәфсир", Җәләлетдин әл-Мәхәлли һәм Җәләлетдин әс-Суюти тарафыннан эшләнгән "Тәфсирүл-Җәләхайн", Гинтаби Мәхмүднең "Тәфсире Тибьян" китапларыннан файдаланганнар.

Инде Корьәни-Кәримнең тел үзенчәлекләренә килгәндә, иң элек аятьләрнең тәрҗемә ителү принципларына игътибар итү зарур. Сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә төгәл мәгънәсен табу мөһим булса, юлга-юл яисә әдәби тәрҗемәләрдә җөмләнең яки тулы текстның мәгънәсен бербөтен итеп аңлату бурычы куела. Болай булмаганда, мәгънәне ялгыш, хәтта бозып аңлату куркынычы бар. "Бу гаять җаваплы эш, - дип ассызыклый билгеле дин белгече Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк. - Тәфсир - Рәсүл Әкрәм хәзрәтләреннән яки сәхабәләреннән дөрес арадашчылар белән күчерелгән риваятьләрдән, гарәп теле булышкан мәгънәләрдән тыш булмаска тиеш. Тәфсир китапларының юк-бар нәрсәләрдән сәламәт булмаулары Ислам өчен куркыныч тудыра. Мәсәлән, күренекле язучы Рабит Батулла, Корьән аятьләренең татарча тәфсирләрен биреп, "Хөҗүрәт (Бүлмәләр)" сүрәсенең 12 нче аятен болай дип аңлата: "Әй, иманлы кешеләр! Уйдырмаларның (гайбәт, имеш-мимешләрнең) күбесеннән ваз кичегез. Аларның байтагы гөнаһ. Кешенең серен сатмагыз, шымчылык кылып, бер-берегезнең гаебен (тырнак астыннан кер) эзләмәгез. Берегез икенчегезнең артыннан (яман) сөйләп калмасын. Үлгән туганының итен ашап, кеше тәм табармы? Бу нәҗес бер гамәл булыр иде. Шулай булгач, (бу харамнарны кылып, гөнаһка батудан) Аллаһтан куркыгыз. Шик юктыр ки, Аллаһ тәүбәләрне кабул итә һәм ярлыкый". Күргәнебезчә, монда авторның әдиплек сәләте эшкә җигелгән.

Шулай итеп, гарәпчәләре бик үк камил булмаганнар өчен дә Корьәни-Кәримнең бик күп татарча тәрҗемәләре һәм тәфсирләре бар. Алардан дөрес һәм нәтиҗәле итеп файдалана белергә генә кирәк.

Элеккеге мәктәп-мәдрәсәләрдә Корьән, тәҗвид (Корьәнне дөрес итеп уку турындагы кагыйдәләр), Корьән тәфсире - иң төп фәннәрдән саналган, аларны өйрәтү өчен шактый күп вакыт сарыф ителгән. Хәзерге дини уку йортларында да Корьәнне өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Бу аңлашыла да: алда күрсәтелгәнчә, Корьән ул - гадел яшәү ысулы, тормыш итү рәвеше, гүзәл әхлакка, пакьлеккә, сафлыкка өндәүче Китап.

Корьәннең дини укыту системасында гына түгел, бәлки дөньяви белем бирү өлкәсендә дә роле арта бара. Бүгенге көндә бөтен кешелек дөньясын хафаландыра торган куркыныч вакыйгалар, хәлләр булып тора, күп сораулар ачык кала. Шуңа күрә Ч.Дарвинның материалистик тәгълиматына карата да башкача фикерләүләр барлыкка килде. Әнә бит, атаклы океанограф Жак-Ив Кусто, дәрьядагы төче һәм тозлы агымнарның бергә кушылмауларының серенә төшенә алмый интеккәч, Корьәнгә мөрәҗәгать итә һәм үзен канәгатьләндергән җавап тапкач, ислам динен кабул итә, иманлы булып бакый дөньяга күчә. Ә андый мисалларны бик күпләп китерергә мөмкин булыр иде.

Инде мәгълүм булганча, 2012 елның 1 сентябреннән илебезнең барлык мәктәпләрендә дә IV-V сыйныф укучылары өчен "Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәнияте нигезләре" (элегрәк ул "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" дип атала иде. - ред.) дип аталган яңа фән кертелде. Бу курсны алып бару өчен әзерлекле белгечләр - ислам дине нигезләре белән хәбәрдар, Изге Китабыбыз - Корьән турында мәгълүматлы укытучылар кирәк, чөнки, беренче чиратта, татар балаларына шул хакта сөйләргә, өйрәтергә кирәк булачак. Бу - гаять җаваплы һәм саваплы вазифа.

Гомумән, дөньякүләм диннәр арасында шактый яшь булган ислам дине һаман куәтләнә, үсә бара. Аның үсешендә, һичшиксез, барлык инсаннар яшәешенең әхлакый яктан формалашуы, гыйлемле, мәгърифәтле булуы өчен туры юл күрсәтүче Изге Китап - Корьәни-Кәрим бәһаләп бетергесез зур әһәмияткә ия.

Мәкалә авторының фотосы www.tataroved.ru сайтыннан алынды.

**Фәрит МИҢНУЛЛИН,**

**филология фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре**

# Әле соң түгел



*Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмәтләреннән кадерле нәрсә - тәрбияле баладыр.*
*(Ризаэддин Фәхреддин)*

**2012 елның 9 декабрендә Россия идарәчеләре РФ Президенты В.В. Путинның ышанычлылары белән очрашты. Очрашу барышында соңгы вакытта илебез халкы гадәткә кертеп җибәргән "әдәп-әхлак", тәртип мәсьәләләре дә игътибардан читтә кала алмады. Мисал өчен, Россия президенты администрациясе җитәкчесе Сергей Иванов: "Кыргыйлашу һәм әхлак түбәнлеге - җитди проблема ул", - диде. Ул яшьләрнең түбәнгә тәгәри баруында массакүләм мәгълүмат чараларының өлеше гаять зур булуын ассызыклады. Моңа кадәр, узган елның сентябрь аенда, В.Путин яшьләрне әхлакый һәм патриотик тәрбияләүгә багышланган киңәшмә үткәргән иде. Димәк, мәсьәлә үтә җитди икән. Ул өстән аска кадәрге һәммә кешегә дә кагыла, барыбызның да баш бәласенә әйләнгән.**

Чыгу юлларын каян эзләргә соң? Яңалык булмаса да языйм. Һәр яшь гаилә кавышкан көненнән туачак балалары турында кайгырта башларга тиеш. Ул иң әүвәл дөрес туклануга һәм күркәм гадәтләргә, чисталык-пөхтәлек, сәламәт яшәү рәвешенә бәйле. Хәрәм ризык белән тукланган әти-әнидән хәрәмнән җыелган тән ярала, ә хәрәмнән яралган тән хәрәмгә тартыла. Бу тормыш чынбарлыгы белән расланган. Эчкече әти-әнидән туган балаларның шактые шул сукмактан атлый башлый. Тәмәке тарткан, фәхешлек белән көн күргән хатын-кызларның язмышы кызларында да кабатлана.

Яңа гына гаилә корган парларга гына түгел, әти буласы егетләргә, әни буласы кызларга да ярдәм кирәк. Чөнки телевизорның кайсы каналын ачып карасаң да исерек, фахишә, наркоманнар белән мыжгып торган тапшыруларга юлыгасың. Артистларның ярым-ялангач чыгышлары гадәти күренешкә әйләнде. Бер көнне кызым белән сөйләшеп торабыз. "Кара әле, - дим, - Лолита озын җиңле, озын күлмәк киеп чыккан". "Булмас, - ди кызым, - я аркасы, я арт саны ачыктыр әле". Чыннан да шулай икән. Аның артыннан ук үтә күренмәле кара колготки, өстеннән кызыл биккини кигән кызлар төркеме пәйда булды.

Бар күргәннәремне дә сөйләп тормыйм инде. Ә әти-әниләргә ярдәм итәрлек ни бар соң? Әдәбият-сәнгать күптән тотнаксызлык сазлыгында. Өстәвенә, Европадан пычрак агып керүен дәвам итә. Анда классик балалар әдәбиятына каршы көрәш оештырып яталар. Имеш, "әти", "әни" сүзләрен әйтергә, язарга ярамый, кеше хокукларын бозу була. Менә сиңа, мә! Хайваннар да парлап-парлап яши ләбаса. Ата каз ата каз белән оя кормый бит!

Көнбатышта балалар өчен җенси азгынлыкны әкияттәгечә мавыктыргыч итеп тасвирлый белә торган "талантлы" язучылар үсеп чыкты. Талантлы дим, чөнки алар дәрәҗәле премияләр ала. Ул әсәрләрне рус теленә тәрҗемә итеп, таратырга теләүчеләре дә табылып кына тора. Хәер, безнекеләр дә кимен куймый: "Пусть говорят"та өчдүрт тапшыруның берсе бәби тапкан бәбиләргә багышлана. Аларны яклыйлар, мактыйлар. (Имеш тапкан, имеш ашата, киендерә һ. б.)

Менә шундый, чәчләрең үрә торырлык шартларда ниләр эшләргә мөмкин соң?

Мин, гадәттә, баш миемне төрледән-төрле сораулар, күңелсез уйлар бораулый башласа, җавап эзләп Җәлил хәзрәт Фазлыев китапларына мөрәҗәгать итәм. Кем соң ул Татарстанның баш казые, Бөрбаш мәчетенең имам-хатыйбы Җәлил хәзрәт?

Җәлил мәктәптә гел "биш"ле билгеләренә генә укыган. Бәлки, бик кечкенәдән әби-бабасыннан, әнисеннән өйрәнгән догалары да ярдәм иткәндер? Сабыйның тырышлыгын Аллаһ Раббыбыз үткен зиһен белән бүләкләгәндер? Аннан соң, ятлау - баланың хәтер сәләтен үстерүдә төп фактор. Монысы фәнни яктан дәлилләнгән.

VII сыйныфта укыганда булачак имам, зиратта, бабасы рухына багышлап, кырык ясин чыга.

Аннан соң совет мәктәбен тәмамлаган егетләр кебек тормыш сукмагыннан атлый. Казан авыл хуҗалыгы институтын кызыл дипломга тәмамлагач, икътисадчы булып районга кайта. Армия хезмәтен дә намус белән үти. Авылның актив яшьләреннән санала. Районның баш икътисадчысы дәрәҗәсенә күтәрелә. Тик беркайчан да иманына хыянәт итми, әби-баба тарафыннан сеңдерелгән рухи кыйммәтләргә тугры булып кала. Кайберәүләр сыман, дингә модага ияреп түгел, иманына тугры калып, белгәннәрен башкаларга да җиткерү теләге көчле булганга килә ул. Җәлил хәзрәтнең әхлак мөгаллимнәренә гел әйтә торган сүзе шул: "Белеме була торып та аны башкаларга җиткермәгән кеше - аркасына китап төягән ишәк өммәтендә". Ягъни һәркайсыбыз дини белемне үзебез өйрәнүдән тыш, башкаларга да җиткерергә бурычлы.

Яшьләр никах мәҗлесләрен, аракысыз туйларны үткәрү өчен Җәлил хәзрәтне чакыра. Районыбызда хәзер юбилей, бәби туе ише истәлекле бәйрәмнәрне дә имам чакырып, туган-тумача, дус-ишне җыеп хәмерсез үткәрү гадәткә кереп бара. Бөтен кеше дә мондый җыеннарга Җәлил хәзрәтне чакыра алмый, шуңа күрә андый ашларны үткәрүдә ярдәмлек кебек берәр кулланма да чыгарылса, халык өчен тагын бер изге эш булыр иде.

Изге гамәлләре бихисап Җәлил әфәнденең. Бөрбаш авылындагы иске мәктәп бинасы аның күңелен бик тә борчый иде. "Куллар-аяклар йөреп торганда, ничек тә балаларны, әти-әниләрне сөендереп, яңа мәктәп салдырасы иде", - дип йөрде ул. Теләген гамәлгә ашыру өчен әле бер, әле икенче җитәкченең ишеген шакыды. Ишеттеләр, сүзен аяк астына салмадылар. Аның инициативасы, җитәкчеләр күрсәткән матди ярдәм белән хәзер авыл уртасында өр-яңа мәктәп балкый. Бүгенге укучылар сөенә-сөенә, мәктәп салуга көче кергән һәркемгә рәхмәт укый-укый һәр иртәдә яңа гыйлем йортының ишекләрен ачып керә. Аның җитәкчелегендә мәктәп коллективы, мәчет әһелләре тырышлыгы белән ел саен мөселман балалары өчен Сабантуй үткәрелә. Тирә-як районнардан, төрле милләттән булган бик күп бала җыела бирегә. Алар да мөселман кануннары буенча әңгәмә корып, үзара тату яшәргә, төрле диннәрне хөрмәт итә белергә өйрәнә. Җ.Фазлыевның мәчетләр, мәктәпләр, мөгаллимнәр, мохтаҗлар, авыру-сырхаулар өчен кылган изгелекләре дә санап бетергесез. Ул гаҗәп сәләтле психолог, оста оратор. Мәктәпләргә, мәчетләргә аның вәгазьләрен тыңларга күпләгән халык җыела. Иренмичә чакырган һәр җиргә барырга тырыша ул. Хәтта ерак районнарга да. Тукта, мин аның китапларының бүгенге бозыклык белән көрәштә яхшы ярдәмлек булуы турында язарга уйлаган идем бит! Әмма автор турында мәгълүмат бирмичә, китаплары турында сөйләп булмас дип уйладым. 2012 елның Корбан гаетен Болгардагы Ак мәчеттә үткәрүен, меңнәрчә кеше йотлыгып тыңларлык вәгазь укуын языйм да, төп максатымны тормышка ашыруга күчәрмен.

Педагог буларак, Җәлил хәзрәтнең киләчәк буынны тәрбияләү, ата-ана/бала мөнәсәбәтләре, әдәп-әхлак кагыйдәләре, ислам дине һәм яшәеш турындагы фәлсәфи, Коръән сүрәләренә нигезләнгән, тормыш чынбарлыгы белән расланган язмаларына еш мөрәҗәгать итәм.

Ризаэддин Фәхреддин: "Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмәтләреннән кадерле нәрсә - тәрбияле баладыр", - дип язган. Баланы шундый итеп тәрбияләү юлларын кайлардан эзләп табарга соң? Моның өчен Җәлил хәзрәтнең "Әти-әниләргә нәсыйхәт" китабын кат-кат укып өйрәнергә кирәктер.

Китап берничә бүлектән тора. Автор аны бала тәрбиясе турында уйланулардан башлый. "Әти, әни, мәхәббәт, гаилә, никах" дип аталган бүлектә автор кешеләр арасындагы эчкерсез мөнәсәбәтләрнең юкка чыга баруына, кешеләрнең нәфес колына әверелүенә ачына. (Мин әллә нигә бер, мәгънәсез булса да, "Давай поженимся" тапшыруын карыйм. Анда безнең ише тир түгеп көн күргән халыктан ачыктан-ачык көлеп утыралар. Алай гына да түгел, яшьләрне байлык колы булырга өндиләр).

"Әти-әнисен калдырган байлыгына карап кына бәяләргә өйрәнгән бала, аларны барыбер булдыксызлыкта гаепләячәк. Картаймыш көнеңдә үзең төзегән зур йортта сиңа урын да калмаска мөмкин", - дип яза китап авторы Җ.Фәзлыев.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв): "Әти-әнинең балага калдырган иң зур мирасы - яхшы тәрбия", - дигән. Нәфеснең чиге юк аның.

Китапта шулай ук "Кем соң ул бала? Ул каян килгән?" кебек сорауларга дәлилле җаваплар да табарга мөмкин. Юкса, бүген кечкенә баланы теләсә кем уйнап карый торган аңсыз курчак дип кабул итәбез... Уенчык бүлешкән бала сыман, аны бүлешә алмыйча, судларга кадәр барып җитәбез.

Әни кеше карынында бала яралганнан алып үзен ничек тотарга, ничек киенергә, ни рәвешле тукланырга тиешлеге китапта җентекләп язылган.

"Никахка салкын карау, никахсыз яшәү ул - киләчәк буын алдында җинаятькә тиң. Кем бүген ирекле мәхәббәт турында сүз алып бара, гаиләнең, никахның әһәмиятен киметергә тырыша, ул кеше - милләтнең киләчәгенә балта чабучы", - ди автор ачынып.

"Бала, аның беренче адымнары" бүлегендә бала туган вакыттан башлап ата-ана өстендә булган төп вазифалар бәян кылына. Балага азан әйтеп күркәм исем кушу - шундый вазифаларның беренчесе. Азан тавышы балага дини юл барлыгын белдерә һәм аны тынычландыра.

Бүген бик күпләрнең тормышта югалып калуларын, сынауларны үтә алмавын автор ышаныч булмауда күрә. "Кеше тормыштан туймасын, кыенлыклар алдында югалып калмасын дисәк, Аллаһка, Аның мәрхәмәтенә ышануны бала вакытта ук тәрбияләргә һәм, бу ышаныч гомер буе югалмасын өчен, моңа бар көчеңне куярга кирәк", - дип яза ул, үз-үзенә кул салучыларның (бигрәк тә балаларның) көннән-көн арта баруына ачынып. Аллаһка ышаныч тәрбияләүне ул табигатьне танырга, яратырга өйрәтү аша башкарырга киңәш итә. Бигрәк тә табигать кочагындагы әңгәмәләрнең үтемле булуына басым ясый. "Әгәр балада табигатьне танып белү теләге уята алсак, белемгә һәм Аллаһны тануга омтылыш тудырдык дигән сүз", - дип нәтиҗә ясый Җәлил хәзрәт.

"Бала һәм дин" дип аталган бүлек "Кешенең күңеленә "дин" орлыгын салу өчен иң кулай вакыт - балачак" дигән фикер белән башлана һәм ул төрле мисаллар белән дәлилләнә.

Авторның: "Бүген кешелек җәмгыятенең рухи кризис кичерүе, эчкечелек, җинаятьчелек күренешләренең артуы, кешеләрнең үз-үзләренә кул салуы үз вакытында аларга дин турында тиешле мәгълүмат бирелмәүдән килә. Әмма балага ислам диненә мәхәббәт тәрбияләү белән бергә, башка диндәгеләрне дә хөрмәт итәргә өйрәтү зарур. Аллаһ Раббыбыз да: "Өйләрдән куып чыгармасалар, көчләп хәрәм ризык ашатмасалар, алар белән тыныч яшәгез", - дигән. Аллаһның бу әмеренә буйсынсак, күпме канкойгыч низаглар булмый калыр, гөнаһсыз гомерләр кыелмас иде.

Диннең төп бурычы - баланың югары рухи үсешен тәэмин итү. Аның ачкычы - Аллаһны тану. Аллаһ турында, фәрештәләр турында сөйләү зарур булса да, баланы кечкенәдән өрәкләр, җеннәр турында сөйләп куркытмаска кирәк. Казан дәүләт медицина академиясе профессоры, медицина фәннәре докторы А.М. Карпов "Самозащита от наркомании" дип аталган китабында: "Гыйбадәт вакытында кеше организмы сәламәтлеккә, психикага уңай йогынты ясый торган шулкадәр көчле, шифалы матдәләр бүлеп чыгара, аны бернинди дә дару алмаштыра алмый", - дип яза.

Җәлил хәзрәтнең китабында иң әһәмиятле бүлекләрнең берсе - "Бала һәм җәмгыять" дигәне. Чөнки баланы җәмгыятьтә үз-үзен тотарга өйрәтү зарур.

Автор туган телгә мәхәббәт тәрбияләү кирәклегенә дә басым ясый. Хәзер инде галимнәр дә ана телендә уйлый белмәгән кешенең фикерләү сәләте түбән булуны исбатлады. Ә татар теле ЮНЕСКО тарафыннан халыкара аралашу теле дип саналган 14 тел арасына кертелгән. "Мөселман кеше теле белән дә, кулы белән дә, гамәле белән дә башкаларны рәнҗетмәс", - дигән Пәйгамбәребез (сгв). Балаларыбыз шундый сыйфатларга ия булсын дисәк, башкаларны хөрмәт итәргә өйрәтү лазем. Ул нәсел-ыруын белергә, уңган-булган сыйфатлары белән горурланырга, кыек юлга кергәннәрдән гыйбрәт алырга тиеш.

Үз-үзен хөрмәт итмәгән бала башкаларны да хөрмәтли белми. Аяныч хәлләргә юлыкмыйк дисәк, нәрсәләрне истә тотарга кирәк соң? Китапта бу турыда да аңлаешлы итеп язылган.

Җәлил хәзрәт Фазлыев - киң эрудицияле, талантлы шәхес. Аның китапларында Коръән аятьләре, пәйгамбәрләребез сөйләгән сүзләр белән бергә Г.Һегель, Р.Фәхреддин, К.Насыйри, М.Акмулла, Г.Тукай һ.б. бүгенге көн язучыларының иҗатларыннан да хикмәтле үрнәкләрне очрата алабыз.

Баласын иманлы, бозыклыклардан имин, белемле, төрле хәлләргә аек бәя бирерлек шәхес итеп күрергә теләгән ата-ана, мөгаллим, җитәкче, гаилә корырга әзерләнгән яшьләргә аның "Иманлы бала", "Әти-әниләргә нәсыйхәт", "Әле соң түгел", "Гомерләр заяга узмасын", "Йөз дә бер вәгазь" һ.б. хезмәтләрен өстәл китабы итеп тотарга, тормышның четерекле, җитди, хәсрәтле һәм куанычлы мизгелләрендә кулга алып, акыллы киңәшләренә колак салырга, Тукай сүзләре белән әйткәндә, укыган шул китапларыбызга рәхмәт әйтергә кирәк.

**Әминә Мөхәммәтҗанова,**
**Балтач районы Шубан авылы**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 7 (176) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35390.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 14 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**